| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

№ 8 «15 » сентябрь 2021 ел

«Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актлар законнары таләпләренә туры китерү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Ялаур авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 7 августындагы 16 номерлы карары белән расланган «Документларның һәм аларның өземтәләренең дөреслеген таныклау» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 1 бүлегенең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы (беренче өлеш) 1994 елның 30 ноябрендәге 51-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ГрК) (РФ законнар җыентыгы, 05 декабрь 1994 ел, №32, 3301 маддә);

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче өлеш) 2000 елның 05 августындагы 117-ФЗ номерлы (алга таба - РФ НК) (РФ законнар җыентыгы, 07 август 2000 ел, №32, 3340 маддә);

1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы нотариат турында Россия Федерациясе законнары Нигезләре (алга таба - Нигезләр) (РФ СНД Җыелма басмасы һәм ВС, 11 март 1993 ел, № 10, 357 маддә);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 06 октябрь 2003 ел, №40, 3822 маддә);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 02 август 2010 ел, №31, 4179 маддә);

Россия Юстиция министрлыгының «Нотариаль гамәлләрне теркәү реестрларының формаларын, нотариаль таныклыкларны, килешүләрдә таныклау язуларын һәм таныклык документларын һәм аларны рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 сентябрендәге 226 номерлы боерыгы белән;

Россия Юстиция министрлыгының «Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр кылу тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 07.02.2020 ел, 16 номерлы боерыгы белән;

«Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасын алып бару тәртибен раслау хакында» 2017 елның 12 маендагы 11н номерлы Федераль казначылык боерыгы;

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03 август 2004 ел);

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге Советының 24.04.2012 ел, № 72 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге Уставы (алга таба-Устав);

Ялаур авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 25 гыйнварында кабул ителгән 3 номерлы карары (алга таба – кагыйдәләр) белән расланган авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба-кагыйдәләр)».

1.2. Регламентның 2 бүлегенең 2.1.бүлекчәсендә «256 номерлы боерык» сүзләрен, «16 нчы боерык» сүләренә алмаштырырга.

1.3. Регламентның 2 бүлегенең 2.5 бүлекчәсендә:

«2. Бер биттән артык булган күчермәләрнең яисә аларның өземтәләренең дөреслеген таныту өчен тапшырылган документлар тегелгән, номерланган һәм документлар җибәрелгән оешма мөһере белән беркетелгән булырга тиеш», сүзләрен:

«2. Күчермәләрнең яисә аларның күләме бер биттән артып киткән өземтәләрнең дөреслеген таныту өчен тапшырылган документлар беркетелергә тиеш.

Документта булган төзәтмәләр яки башка җитешсезлекләр документ тәкъдим ителгән максатлар өчен мөһим булмаса, җирле үзидарәнең вазыйфаи заты мондый документны күчермәнең дөреслеген таныклау өчен кабул итәргә хокуклы.» сүзләренә алмаштырырга;

«256 номерлы боерык» сүзләрен, «16 нчы боерык» сүләренә алмаштырырга.

1.4. Регламентның 2 бүлегенең 2.6.бүлекчәсендә «19н номерлы боерык» сүзләрен, «11н боерыгы» сүләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе О.В.Охотникова